ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№533 от «18» 05 2016 г.

2016 елда Мамадыш муниципаль
районы территориясендә төп гомуми
белем бирүнең мәгариф программаларын
үзләштергән белем алучыларның
Дәүләт йомгаклау аттестациясен
үткәрү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның 59 статьясындагы 12 һәм 13 өлешләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.01.2016 ел, 52 – б санлы боерыгы нигезендә, төп гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштергән белем алучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты
к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ “Мәгариф бүлегенә” (Габдрахманов И.Н.):
- 2016 елда төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрүне тәэмин итәргә;
- 2016 елда Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне һәм Россия халыклары әдәбиятын туган телдә өйрәнгән һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен алар буенча имтихан сайлаган төп гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучылар өчен республика имтиханы үткәрергә;
- үз компетенциясе чикләрендә Дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрүнең мәгълүмати һәм норматив – хокукый яктан тәэмин итәргә;
- Дәүләт йомгаклау аттестациясен инструктив- методик, оештыру һәм мәгълүмати яктан тәэмин итәргә.

2. Дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрү пунктлары итеп МБГБУ “Мамадыш шәһәре ак. К.Ә.Вәлиев исемендәге 2 нче номерлы лицейны”, МБГБУ “Мамадыш шәһәре өченче номерлы урта гомуми белем мәктәбен” билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Сергеев А.М.) 2016 елда Дәүләт йомгаклау аттестациясен, шул исәптән республика имтиханын үткәрү

чыгымнарын финанслар белән тәэмин очен каралган акчаларның Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ “Мәгариф бүлегенең” нормативлар билгеләнгән  сметасына нигезләнеп, үз вакытында күчүен тәэмин итәргә.

4. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлегенә төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен, шул исәптән республика имтиханын үткәрү пунктлары янындагы территорияләрдә җәмәгать тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә белем бирү оешмалары администрацияләренә булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Мамадыш үзәк район хастаханәсенә (Хазиев Д.Ф.) төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен, шул исәптән республика имтиханын үткәрү пунктларында медицина персоналы кизүен оештыруда булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П.Смирновага йөкләргә.

Җитәкче С.М. Гыйматранов